КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № 870

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2023 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2023 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 апрель, 263 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «(2020 – 2023)» саннарын «(2020 – 2024)» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «(2020 – 2023)» саннарын «(2020 – 2024)» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2023 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «(2020 – 2023)» саннарын «(2020 – 2024)» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа исеме | «2020 – 2024 елларга татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Программа)»; |

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары | 2020 – 2024 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 489 109,67 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2020 елда – 70 498,7 мең сум;<br>2021 елда – 109 432,1 мең сум;<br>2022 елда – 116 935,6 мең сум;<br>2023 елда – 96 121,6 мең сум;<br>2024 елда – 96 121,6 мең сум.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>Программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаны, бюджеттан тыш акчаны (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) һәм муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасын файдалану күздә тотыла»; |

«Программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Программаны тормышка ашыру 2024 елга түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Россия Федерациясе төбәкләренең гомуми саныннан Программа чараларында катнашкан төбәкләрнең өлешен 60 процентка кадәр арттырырга;<br>татарларның матди һәм матди булмаган, өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган мирас объектлары санын 2020 ел белән чагыштырганда 122 проценттан күбрәк арттырырга (2020 ел – 612 берәмлек, 2024 ел – 752 берәмлек);<br>эшкәртелгән һәм музей фондларына тапшырылган |

| | |
|---|---|
| | археологик артефактлар (Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарлар тарихы һәм мәдәнияте буенча) санын 1 000 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>татарларның туган телен һәм мәдәниятен өйрәнү буенча эшләнгән укыту-методик комплекслары, укыту программалары һәм ярдәмлекләр санын 31 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>Россия Федерациясендә татарлар тупланып яши торган һәм сакланып калган торак пунктлары белән тикшерелгән төбәкләрне колачлауны 51 процентка кадәр арттырырга;<br>Программа чараларының гомуми саныннан интеллектуаль потенциалны арттыруга юнәлдерелгән чаралар өлешен 34 процентка кадәр арттырырга;<br>Программа чараларының гомуми саныннан медиа-проектлар форматындагы чаралар өлешен 52 процентка кадәр арттырырга»; |

Программаның II бүлегендәге сигезенче абзацында «2020 – 2023» саннарын «2020 – 2024» саннарына алмаштырырга;

Программаның III бүлегендәге икенче – алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 489 109,67 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2020 елда – 70 498,7 мең сум;

2021 елда – 109 432,1 мең сум;

2022 елда – 116 935,6 мең сум;

2024 елда – 96 121,6 мең сум.

2024 елда – 96 121,6 мең сум.»;

Программага 1, 2 кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин